МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.10.2019 Казан ш. № 21-41-249

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1602-1 статьясындагы 6 һәм 7 пунктлары нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Бу боерыкның 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.
4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
23.10.2019 ел, №21-41-249
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү
тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Боерык Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^{2-1}$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктлары нигезендә эшләнгән, һәм ул Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләргә, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторларына, Татарстан Республикасы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларына (алга таба – бюджет средстволарының баш администраторлары) карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип максатыннан, бюджет средстволарының баш администраторларына карата финанс сыйфатына мониторинг төшенчәсе (алга таба – финанс менеджменты сыйфатына мониторинг) бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан, бюджет законында билгеләнгән, активлар белән идарә итүнең, дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуның сыйфатын һәм бюджет средстволарыннан файдалануның нәтиҗәлелеген, бюджет учетын алып баруның һәм бюджет хисабын төзүнең, эчке финанс контрольлеген хәл кылуның сыйфатын үз эченә алучы бюджет вәкаләтләрен бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан үтәү процесслары һәм процедуралары җыелмасына анализ ясауны һәм бәяләүне аңлата.

3. Финанс менеджменты сыйфатына мониторинг Министрлык тарафыннан өч юнәлеш буенча үткәрелә һәм түбәндәгеләрдән тора:

финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг (ел башыннан үсеп баручы йомгак белән, агымдагы финанс елының беренче кварталы, беренче яртыеллыгы, тугыз ае йомгаклары буенча үткәрелә);

хисап финанс елында финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг;

чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турындаТатарстан Республикасы законы проектын төзүдә файдаланыла торган документлар ягыннан, финанс менеджменты сыйфатына мониторинг.

4. Финанс менеджменты сыйфатына еллык, кварталлык мониторинг, шулай ук чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын төзүдә файдаланыла торган документлар ягыннан, финанс менеджменты сыйфатына мониторинг, түбәндәге документлар нигезендә, бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге күрсәткечләрдән файдаланып үткәрелә:

Министрлыкка бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан тапшырылган бюджет хисабы, мәгълүматлр һәм материаллар;

Бюджет үтәлешенә контрольлек итүнең автоматлаштырылган үзәге – Бюджетны үтәүне һәм бюджет процессы белән идарә итүне автоматлаштыруның комплекслы системасында («АЦК-Финансы») чагылдырылган мәгълүматлар;

“Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар карамагындагы учреждениеләрнең бухгалтерия учеты һәм хисабы” Татарстан Республикасы Дәүләт мәгълүмат системасында чагылдырылган мәгълүматлар;

бөтен кеше өчен ачык (бастырып чыгарылган яки рәсми сайтларга урнаштырылган) мәгълүматлар.

## II. Финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрүне оештыру

5. Бюджет средстволарының баш администраторлары Министрлыкка тапшыра:

5.1. финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг үткәрү максатыннан, хисап чорыннан соң килүче айның 20нче числосына кадәр хисап чоры өчен түбәндәге мәгълүматларны:

финанс менеджменты сыйфатына еллык (кварталлык) мониторинг күрсәткечләрен исәпләү өчен кирәкле булган бу Тәртипкә №1 кушымтада күздә тотылган финанс менеджменты өлкәсендә расланган хокукый актларның күчермәләрен һәм (яки) финанс менеджменты өлкәсендә элек тапшырылган хокукый актларга үзгәрешләрне;

бу Тәртипкә №1 кушымтаның 3 пункты нигезендә финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг күрсәткечләрен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләренә йогынты ясардай тармак үзенчәлекләре турында мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №3 кушымта нигезендәге форма буенча, Татарстан Республикасы

дәүләт программаларын һәм ведомстволарның максатчан программаларын һәм дәүләт заданиеләрен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре суммалары турында мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №7 кушымта нигезендәге форма буенча, Татарстан Республикасы бюджетыннан кирәгеннән артыграк түләнү (түләтелү) сәбәпле кире кайтарылган (капланган) средстволар суммалары турында мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №11 кушымта нигезендәге форма буенча, сатып алуларны планлаштыру кагыйдәләрен үтәмәүләр ачыкланган бюджет средстволарының баш администраторлары һәм алар карамагындагы бюджет средстволарын алучылар тарафыннан товарлар җибәрүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары турында мәгълүматлар;

5.2. хисап финанс елында агымдагы финанс елының 15 февраленә кадәр финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг үткәрү максатыннан, түбәндәге мәгълүматларны:

бу пунктның 5.1 пунктчасында күздә тотылган мәгълүматларны;

бу Тәртипкә №1 кушымтаның 3 пункты нигезендә финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг күрсәткечләрен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны;

бу Тәртипкә №4 кушымта нигезендәге форма буенча законлы көченә кергән дәгъва таләпләре һәм суд карарлары турында мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №5 кушымта нигезендәге форма буенча бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының финанс (финанс-икътисади) подразделениесенең кадрлары турында мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №6 кушымта нигезендәге форма буенча, бюджет учеты һәм хисабын автоматлаштыру турында мәгълүматлар;

бу Тәртипкә №12 кушымта нигезендәге форма буенча, бюджет средстволарының баш администраторына җибәрелгән Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Министрлык күрсәтмәләрен үтәү турында мәгълүматлар.

## III. Финанс менеджментының сыйфат күрсәткечләрен исәпләү һәм финанс менеджменты сыйфатына мониторинг нәтиҗәләре турында хисап булдыру тәртибе

6. Министрлык бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендә финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләрен исәпләүне хәл кыла һәм, бу Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлардан файдаланып, финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг һәм еллык мониторинг нәтиҗәләре турында хисаплар булдыра.

6.1. Министрлык, финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг үткәрү максатыннан чыгып, хисап чорыннан соң килүче айның 30нчы числосына кадәр, үзгәртү чоры бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендә кварталга туры килгән финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләрен исәпләүне хәл кыла.

Үзгәртү чоры бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендә елга туры килгән финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләре финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг үткәрүдә исәпләнелгән тиешле күрсәткечләргә бертигез дәрәҗәдә кабул ителә.

6.2. Министрлык, финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг үткәрү максатыннан чыгып, агымдагы финанс елының 10 маена кадәр, бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге форма буенча, финанс менеджментының барлык сыйфат күрсәткечләрен исәпләүне хәл кыла.

7. Министрлык финанс менеджментының сыйфаты күрсәткечләрен исәпләү мәгълүматлары нигезендә, түбәндәге формула буенча бюджет средстволарының һәр администраторы буенча финанс менеджменты сыйфатын йомгаклау бәяләвен исәпләп чыгара:

$$\mathrm{E} = 100\sum_i S_i k_i \sum_j S_{ij} E(P_{ij}),$$

биредә

Е – бюджет средстволарының баш администраторы буенча йомгаклау бәяләмәсе;

$S_i$ – финанс менеджментының i-нче төркеме сыйфат күрсәткечләре өлеше;

$k_i$ – финанс менеджментының i-нче төркеме сыйфат күрсәткечләрен бәяләүне үзгәртүче коэффициент;

$S_{ij}$ – финанс менеджментының i-нче төркеме сыйфат күрсәткечләрендәге финанс менеджменты сыйфатының j-нчы күрсәткече өлеше;

$E(P_{ij})$ – финанс менеджментының i-нче төркеме сыйфат күрсәткечләрендәге финанс менеджменты сыйфатының j-нчы күрсәткече буенча бәяләү.

Бюджет средстволарының баш администраторы өчен финанс менеджментының сыйфат күрсәткече (күрсәткечләр төркеме) исәпләнелмәгән очракта, финанс менеджменты сыйфатының әлеге күрсәткече (күрсәткечләр төркеме) өлеше финанс менеджменты сыйфатының башка күрсәткечләре (күрсәткечләр төркеме) буенча пропорциональ рәвештә бүленә.

8. Финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг һәм финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг нәтиҗәләре турында хисаплар Министрлык тарафыннан, бюджет средстволарының баш администраторлары буенча финанс менеджменты сыйфатын йомгаклау бәяләве күрсәткечләрен һәм аларны исәпләү өчен кулланылган барлык күрсәткечләрне күрсәтеп, бюджет средстволарының баш администраторлары буенча булдырыла.

9. Финанс менеджменты сыйфатына мониторинг нәтиҗәләре Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

## IV. Финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләренә йогынты ясардай тармак үзенчәлекләре турында мәгълүматлар тутыруга карата таләпләр

10. Финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләренә йогынты ясардай тармак үзенчәлекләре турында мәгълүматлар (бу тәртипкә №2 кушымта) тутырутүбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

10.1. финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечен исәпләү өчен кулланыла торган һәр параметр буенча 1 графада бу Тәртипкә кушымтаның тиешле номеры күрсәтелә;

10.2. 2 графада бу Тәртипкә №1 яки №10 кушымталардан күрсәткеч номеры күрсәтелә;

10.3. 3 графада бу Тәртипкә №1 яки №11 кушымталардан күрсәткеч параметрының билгеләнеше күрсәтелә;

10.4. 4 графада күрсәткеч параметрын үзгәртү берәмлеге күрсәтелә;

10.5. 5 графада Россия Федерациясе бюджеты классификациясенең кеермнәр (чыгымнар) классификациясе коды күрсәтелә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары буенча бюджет средстволарының баш администраторы коды, чыгымнар бүлеге, бүлекчәсе, максатчан статьясы һәм төре күрсәтелергә тиеш;

10.6. 6 графада, әлеге параметрның үлчәү берәмлекләрендә, параметрның максатчан (пландагы) күрсәткече күрсәтелә;

10.7. 7 графада әлеге параметрның үлчәү берәмлекләрендә, параметрның факттагы күрсәткече күрсәтелә;

10.8. 8 графада параметрның максатчан һәм факттагы күрсәткечләре аермасы

булып торган, параметрның максатчан күрсәткеченнән тайпылыш күрсәтелә;

10.9. 9 графада параметрның максатчан күрсәткеченнән тайпылыш проценты күрсәтелә;

10.10. 10 графада бюджет средстволарының баш администраторы гамәлләренә бәйле булмаган, параметрның максатчан күрсәткеченнән тайпылыш сәбәпләре күрсәтелә.

## V. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын һәм дәүләт заданиеләрен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре суммалары турында мәгълүматлар тутыруга карата таләпләр

11. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын һәм дәүләт заданиеләрен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре суммалары турында мәгълүматлар тутыру (бу Тәртипкә №3 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

11.1. финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг үткәрелгәндә хисап финанс елында гамәлдә булып килгән норматив-хокукый актлар нигезендә мәгълүматлар күрсәтелә;

11.2. финанс менеджменты сыйфатына кварталлык мониторинг үткәрелгәндә агымдагы финанс елында гамәлдә булып килгән норматив-хокукый актлар нигезендә мәгълүматлар күрсәтелә;

11.3. 1 графада Татарстан Республикасы дәүләт программалары, ведомство максатчан программалары, дәүләт заданиеләре атамалары күрсәтелә;

11.4. 2 графада артып бару тәртибендә, юл коды күрсәтелә: Татарстан Республикасы дәүләт программалары өчен – 011дән башлап; ведомство максатчан программалары өчен – 101дән башлап; дәүләт заданиеләре өчен – 201дән башлап.

11.5. 3 – 5 графаларда:

- финанс менеджменты сыйфатына еллык мониторинг үткәрелгәндә күрсәтелә:

Татарстан Республикасы һәр дәүләт программасы өчен, ведомство максатчан программасы һәм һәр дәүләт заданиесе өчен – хисап финанс елына, агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга тиешле программаны яки тиешле дәүләт заданиесен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә күздә тотылган, хисап финанс елына, агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджетның җыелма бюджет росписе нигезендә, хисап елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына үзгәрешләрдән чыгып, бюджет ассигнованиеләре суммасы;

300 юлы буенча – хисап финанс елына, агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджетның җыелма бюджет росписе нигезендә, хисап елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына үзгәрешләрдән чыгып, физик һәм юридик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен бюджет средстволарының баш администраторына күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре суммалары;

310 юлы буенча – хисап финанс елына, агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджетның җыелма бюджет росписе нигезендә, хисап елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына үзгәрешләрдән чыгып, бюджет средстволарының баш администраторына күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре суммалары;

- финанс менеджментына кварталлык мониторинг үткәрелгәндә күрсәтелә:

Татарстан Республикасы һәр дәүләт программасы өчен, ведомство максатчан программасы һәм һәр дәүләт заданиесе өчен – агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга тиешле программаны яки тиешле дәүләт заданиесен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә күздә тотылган, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджетның җыелма бюджет росписе нигезендә, хисап чоры ахырына андагы үзгәрешләрдән чыгып, бюджет ассигнованиеләре суммалары;

300 юлы буенча – агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга физик һәм юридик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бюджет средстволарының баш администраторына күздә тотылган, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджетның җыелма бюджет росписе нигезендә, хисап чоры ахырына андагы үзгәрешләрдән чыгып, бюджет ассигнованиеләре суммалары;

310 юлы буенча – агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджет средстволарының баш администраторына күздә тотылган, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджетның җыелма бюджет росписе нигезендә, хисап чоры ахырына андагы үзгәрешләрдән чыгып, бюджет ассигнованиеләре суммалары.

## VI. Дәгъва таләпләре һәм законлы көченә кергән суд карарлары турында мәгълүматлар тутыруга карата таләпләр

12. Дәгъва таләпләре һәм законлы көченә кергән суд карарлары турында мәгълүматлар тутыру (бу тәртипкә №4 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

12.1. 3 графада хисап финанс елында суд дәгъваларының тиешле төрләре буенча үзләренә карата кабул ителеп, законлы көченә кергән игълан ителгән дәгъва таләпләренең акчалата гомуми суммасы күрсәтелә, мең сумнарда, икенче вакланма дистәгә кадәр төгәллек белән;

12.2. 4 графада хисап финанс елында суд дәгъваларының тиешле төрләре буенча суд тарафыннан суд карарлары буенча түләтүгә билгеләнеп, законлы көченә кергән канәгатьләндерелгән дәгъва таләпләренең гомуми суммасы күрсәтелә, мең сумнарда, икенче вакланма дистәгә кадәр төгәллек белән;

12.3. 5 графада хисап финанс елында суд дәгъваларының тиешле төрләре буенча игълан ителгән дәгъва таләпләренең гомуми күләме күрсәтелә;

12.4. 6 графада суд дәгъваларының тиешле төрләре буенча дәгъва таләпләрен тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерүне күздә тоткан, законлы көченә кергән суд карарларының гомуми саны күрсәтелә;

12.5. “Барлыгы” юлының 3 – 6 графаларында суд дәгъваларының барлык төрләре буенча йомгаклау суммасы күрсәтелә.

## VII. Бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының финанс (финанс-икътисад) подразделениесе кадрлары турында мәгълүматлар тутыруга карата

таләпләр

13. Бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының финанс (финанс-икътисад) подразделениесе кадрлары турында мәгълүматлар тутыру (бу Тәртипкә №5 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

13.1. 1 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының финанс (финанс-икътисад) подразделениесе (департамент, идарә) атамасы һәм бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының финанс (финанс-икътисад) подразделениесе составына керүче бүлекләр атамалары күрсәтелә. Бюджет средстволарының баш администраторы аппаратында мөстәкыйль финанс (финанс-икътисад) подразделениесе (департамент, идарә) булмаганда, бюджет средстволарының баш администраторы эшчәнлегенең финанс (финанс-икътисад) юнәлешен алып баручы бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының структур подразделениесе (департамент, идарә) атамасы күрсәтелә, шуннан соң "(өлешчә") дигән искәрмә һәм тиешле функцияләр үтәүне тәэмин итүче бүлекләр (алга таба – финанс (финанс-икътисад) бүлекләре) атамалары күрсәтелә;

13.2. 2 графада, 01дән башлап, артып бару тәртибендә юл коды күрсәтелә;

13.3. 3 графада, штат расписаниесе нигезендә, бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесе (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлеге хезмәткәрләренең саны күрсәтелә;

13.4. 4 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесе (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлеге хезмәткәрләренең факттагы саны күрсәтелә;

13.5. 5 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесенең (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлегенең икътисад фәннәре кандидаты яки докторы дипломнарына ия булучы хезмәткәрләре саны күрсәтелә;

13.6. 6 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесенең (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлегенең икътисади юнәлешләр (белгечлекләр) буенча югары һөнәри белем яки һөнәри яктан яңадан әзерләнү турында дипломнарга ия булучы, икътисад фәннәре кандидаты яки докторы дипломнарына ия булмаучы хезмәткәрләре саны күрсәтелә;

13.7. 7 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесенең (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлегенең икътисади юнәлешләр (белгечлекләр) буенча урта һөнәри белем яки һөнәри яктан яңадан әзерләнү турында дипломнарга ия булучы хезмәткәрләре саны күрсәтелә;

13.8. 8 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесенең (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлегенең соңгы өч ел эчендә икътисад һәм финанс өлкәсендә квалификация күтәрүне узу турында таныклыкларга (сертификатлар, шаһәдатнамәләр) ия булучы хезмәткәрләре саны күрсәтелә;

13.9. 9 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының

тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесенең (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлегенең хисап финанс елының 1 гыйнварына подразделениедә өч елдан артыграк эш стажына ия булучы 35 яшькә кадәрге хезмәткәрләре саны күрсәтелә;

13.10. 10 графада бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының тиешле финанс (финанс-икътисад) подразделениесенең (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлегенең агымдагы финанс елының 1 гыйнварына подразделениедә өч елдан артыграк эш стажына ия булучы 35 яшькә кадәрге хезмәткәрләре саны күрсәтелә;

13.11. “Барлыгы” юлында 3 – 10 графаларда бюджет средстволарының баш администраторы аппаратының барлык финанс (финанс-икътисад) подразделениеләре (департамент, идарә), финанс (финанс-икътисад) бүлекләре буенча күрсәткечләре суммасы күрсәтелә.

## VIII. Бюджет учетын һәм хисабын автоматлаштыру турында мәгълүматларны тутыруга карата таләпләр

14. Бюджет учетын һәм хисабын автоматлаштыру турында мәгълүматларны тутыру (бу Тәртипкә №1 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

14.1. 1 графада бюджет средстволарының баш администраторы карамагындагы бюджет средстволарын алучыларның гомуми саны күрсәтелә;

14.2. 2 графада “Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар кармагындагы учреждениеләрнең бухгалтерия учеты һәм хисабы” Татарстан Республикасы Дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган бюджет средстволарының баш администраторы карамагындагы бюджет средстволарын алучыларның гомуми саны күрсәтелә;

14.3. 3 графада бюджет учетын автоматлаштыру буенча программа комплексларыннан файдаланучы бюджет средстволарының баш администраторы карамагындагы бюджет средстволарын алучыларның гомуми саны күрсәтелә.

Бюджет средстволарының баш администраторы карамагында бюджет средстволарын алучылар булмаганда, әлеге кушымта тутырылмый.

## IX. Татарстан Республикасы бюджетыннан кирәгеннән артык түләнгән (түләтелгән) булуы сәбәпле кире кайтарылган (капланган) суммалар турында мәгълүматлар тутыруга карата таләпләр

15. Татарстан Республикасы бюджетыннан кирәгеннән артык түләнгән (түләтелгән) булуы сәбәпле кире кайтарылган (капланган) суммалар турында мәгълүматлар тутыру (бу Тәртипкә №7 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

15.1. 1 графада Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторы (алга таба – бюджет керемнәренең баш администраторы) атамасы күрсәтелә;

15.2. 2 графада бюджет керемнәренең баш администраторы коды күрсәтелә;

15.3. 3 графада хисап чорында бюджет керемнәренең баш администраторы һәм (яки) бюджет керемнәренең баш администраторы карамагындагы бюджет керемнәре

администраторлары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетка кирәгеннән артык түләнгән (түләтелгән) булуы сәбәпле (Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган салымнардан, ачыкланмаган акча керемнәреннән, субсидияләр, субвенцияләр калдыкларыннан һәм башка бюджетара трансфертлардан тыш) кире кайтарылган (капланган) суммалар күрсәтелә;

## X. Татарстан Республикасы бюджеты средстволарына түләтүне күздә тоткан суд актларын үтәү процедураларын бозуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында бюджет средстволарын алучыларга ачылган лицевой счетларда средстволарны тоту буенча операцияләрне туктатып тору турында мәгълүматлар тутыруга карата таләпләр

16. Татарстан Республикасы бюджеты средстволарына түләтүне күздә тоткан суд актларын үтәү процедураларын бозуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында бюджет средстволарын алучыларга ачылган лицевой счетларда средстволарны тоту буенча операцияләрне туктатып тору турында мәгълүматлар тутыру (бу Тәртипкә № 8 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

16.1. 1 графада бюджет средстволарының баш администраторы атамасы күрсәтелә;

16.2. 2 графада бюджет средстволарының баш администраторы коды күрсәтелә;

16.3. 3 графада хисап чорында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.4 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарына түләтүне күздә тоткан суд актларын үтәү процедураларын бозуга бәйле рәвештә, Министрлыкта бюджет средстволарының баш администраторы карамагындагы бюджет средстволарын алучыларга ачылган лицевой счетларда средстволарны тоту буенча операцияләрне туктатып тору турында Министрлык тарафыннан җибәрелгән уведомлениеләр саны күрсәтелә;

16.4. 4 графада хисап чорына кадәр килгән елда, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.4 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарына түләтүне күздә тоткан суд актларын үтәү процедураларын бозуга бәйле рәвештә, Министрлыкта бюджет средстволарының баш администраторы карамагындагы бюджет средстволарын алучыларга ачылган лицевой счетларда средстволарны тоту буенча операцияләрне туктатып тору турында Министрлык тарафыннан җибәрелгән уведомлениеләр саны күрсәтелә.

## XI. Үзләрендә сатып алуларны планлаштыру кагыйдәләрен үтәмәү ачыкланган, бюджет средстволарының баш администраторлары һәм алар кармагындагы бюджет средстволарын алучылар тарафыннан төзелгән товарлар җибәрүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары турында мәгълүматлар тутыруга карата таләпләр

17. Үзләрендә сатып алуларны планлаштыру кагыйдәләрен үтәмәү ачыкланган, бюджет средстволарының баш администраторлары һәм алар кармагындагы бюджет

средстволарын алучылар тарафыннан төзелгән товарлар җибәрүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары турында мәгълүматлар тутыру (бу Тәртипкә №11 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

17.1. 1 графада бюджет средстволарының баш администраторлары атамасы күрсәтелә;

17.2. 2 графада, бюджет классификациясе белән, бюджет средстволарының баш администраторлары кодлары күрсәтелә;

17.3. 3 графада тиешле бюджет средстволарының баш администраторы һәм аның карамагындагы бюджет средстволарын алучылар төзегән дәүләт контрактларының гомуми бәясе күрсәтелә;

17.4. 4 графада үзләрендә сатып алуларны планлаштыру кагыйдәләрен үтәмәү ачыкланган, бюджет средстволарының баш администраторлары һәм алар кармагындагы бюджет средстволарын алучылар тарафыннан төзелгән дәүләт контрактларының гомуми суммасы күрсәтелә.

17.5. 5 графада үзләрендә закон нигезендә административ җаваплылыкка тартуга китергән сатып алуларны планлаштыру кагыйдәләрен үтәмәү ачыкланган, бюджет средстволарының баш администраторлары һәм алар кармагындагы бюджет средстволарын алучылар тарафыннан төзелгән дәүләт контрактларының гомуми суммасы күрсәтелә.

## XII. Бюджет средстволарының баш администраторына җибәрелгән Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы күрсәтмәләрен үтәү турында мәгълүматларны тутыруга карата таләпләр

18. Бюджет средстволарының баш администраторына җибәрелгән Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы күрсәтмәләрен үтәү турында мәгълүматларны тутыру (бу Тәртипкә №12 кушымта) түбәндәге таләпләрдән чыгып хәл ителә:

18.1. 1 графада бюджет средстволарының баш администраторына Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җибәрелгән күрсәтмәләр саны күрсәтелә;

18.2. 2 графада бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан үтәлгән Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы күрсәтмәләренең саны күрсәтелә;

18.3. 3 графада бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан үтәлмәгән (өлешчә үтәлгән) Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы күрсәтмәләренең саны күрсәтелә;

18.4. 4 графада Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы күрсәтмәләренең бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан үтәлмәү (өлешчә үтәлмәү) сәбәпләре күрсәтелә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибенә №1 кушымта

# БЮДЖЕТ СРЕДСТВОЛАРЫ БАШ АДМИНИСТРАТОРЛАРЫНЫҢ ФИНАНС МЕНЕДЖМЕНТЫ СЫЙФАТЫНА ЕЛЛЫК МОНИТОРИНГ (КВАРТАЛЛЫК МОНИТОРИНГ) КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

| Күрсәткеч атамасы | Күрсәткеч исәпләмәсе | Үлчәү берәмлеге | Билге | | Күрсәткечнең саллылыгы | Аңлатма |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Бюджетное планирование | | % | | | 30 | |
| 1.1. Чыгымнарны планлаштыруның сыйфаты:Татарстан Республикасының җыелма бюджет росписенә үзгәрешләр суммасы өлеше[1] | $P = 100 \times S_i / b$, бирелә:<br><br>$S_i$ – “Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджер росписьләрен төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында” 02.04.2010 № 02-29 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгының 11 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә кертелә торган Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписендәге һәм бюджет йөкләмәләре лимитларындагы уңай үзгәрешләр суммасы;<br>n – бюджет ассигнованиеләре арткан очракта “Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджер росписьләрен төзү һәм алып бару | % | P=0; n=0 | 5 | 20 | Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписендәге һәм бюджет йөкләмәләре лимитларындагы үзгәрешләр турында белешмәләрнең күп санда булуы бюджет средстволарының баш администраторының финанс ягыннан планлаштыру буенча начар эшләве турында сөйли.<br>Максатчан ориентир: P=0.<br>Күрсәткеч, ел саен, квартал саен, тармак үзенчәлекләреннән чыгып исәпләнелә. |
| | | | P<15%; n=1 | 4 | | |
| | | | P<15%; n=2 | 3 | | |
| | | | P<15%; n=3 | 2 | | |
| | | | P<15%; 3>n≥5 | 1 | | |
| | | | P<15% | 0 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәртибен раслау турында” 02.04.2010 № 02-29 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгының 11 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә кертелә торган Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписендәге һәм бюджет йөкләмәләре лимитларындагы үзгәрешләрнең саны;<br>b – хисап чоры азагына кертелгән үзгәрешләрдән чыгып, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписе нигезендә бюджет средстволарының баш администраторларының бюджет ассигнованиеләре күләме. | | | | | |
| 1.2. Бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектын төзегәндә агымдагы финанс елында эшләнелә торган Татарстан Республикасы законы проектларын, документлар һәм материалларны әзерләү һәм карап тикшерү графигы нигезендә, документларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына үзвакытында тапшыру[1] | $t_i$ – чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектын төзегәндә агымдагы финанс елында эшләнелә торган Татарстан Республикасы законы проектларын, документлар һәм материалларны әзерләү һәм карап тикшерү графигы нигезендә, бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан документларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру датасыннан тайпылу көннәре саны | % | $t_i$=0<br>$t_i$=1<br>$t_i$=2<br>$t_i$=3<br>$t_i$=4<br>$t_i$=5 | 5<br>4<br>3<br>2<br>1<br>0 | 20 | Күрсәткечнең уңай булуы бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан документларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру срогы үтәлмәү турында сөйли.<br>Максатчан ориентир: 0<br>Күрсәткеч ел саен исәпләнелә. |
| 1.3. Бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан бюджет ассигнованиеләренең нигезләнешләрен әзерләүнең сыйфаты[1] | $P = \frac{1}{N} * \sum_{i=1}^{N} \frac{O_{id}}{O_i}$, где:<br>$O_{id}$ – чыгымнар төренең i-нче төркеме буенча, чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты проектын булдыру максатыннан чыгып тапшырылган, әмма Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының структур подразделениеләре инкарь иткән нигезләнешләр саны;<br>$O_i$ – чыгымнар төренең i-нче төркеме буенча, чираттагы финанс елына һәм планда | % | P≤2%<br>2%<P≤5%<br>5%<P≤15%<br>15%<P≤30%<br>30%<P≤40%<br>P<40% | 5<br>4<br>3<br>2<br>1<br>0 | 30 | Күрсәткеч бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан д Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган бюджет ассигнованиеләре нигезләнешләрен әзерләүнең сыйфатын күрсәтә, аларның бюджет законнарына, чыгым йөкләмәләре килеп чыгуның хокукый нигезләренә, бюджет ассигнованиеләре |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты проектын булдыру максатыннан чыгып Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылган бюджет ассигнованиеләре нигезләнешләренең гомуми саны;<br>N – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылган бюджет ассигнованиеләре нигезләнешләрендәге чыгымнар төрләренең төркемнәре саны. | | | | | нигезләнешләрен булдыру һәм тапшыру кагыйдәләренә туры килү-килмәвен кертеп.<br>включая их соответствие<br>Максатчанориентир: 0%<br>Күрсәткеч, тармак үзенчәлекләреннән чыгып, ел саен исәпләнелә. |
| 1.4. Бюджет ассигнованиеләренә ихтыяҗ[1] | , биредә:<br><br>әгәр $0<P_i<10\%$,<br><br>$P_i = \frac{10 - P_i}{10}$ , биредә:<br><br>әгәр $P_i \geq 10\%$, то $P_i=0$<br><br>$P_1 i = 100 * (1 - S_1 fi / S_1 pi)$ ), где:<br>$КР_{ПСБ}$ – хисап чорында Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган субсидияләр хисабына Татарстан Республикасы дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең касса чыгымнары күләме;<br>$КР_{ГРБС}$ – Татарстан Республикасы дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренә бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан субсидияләр рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан күчерелгән средстволар күләме;<br>N – хисап чоры башына расланган, әмма үзләре буенча бюджет ассигнованиеләре файдаланылмаган җыелма бюджет росписендәге күрсәткечләр саны;<br>Spi – хисап чоры башына расланган җыелма бюджет росписенең i-нче күрсәткече буенча сумма;<br>Sfi – хисап чоры башына расланган җыелма бюджет росписенең i-нче күрсәткече буенча касса түләлеше; | % | E(P)=k*100*P<br>k=0, хисап чорында Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматларны тапшырмауга яки срокларын санга сукмыйча тапшыруга бәйле бозулар ачыкланган очракта<br>k=1, мондый бозулар булмаган очракта | | 30 | Күрсәткеч чыгымнар буенча тиешле күрсәткеч буенча бюджет турында Татарстан Республикасы законы проектын төзегәндә бюджет средстволарының баш администраторы тарафыннан бюджет тапшырылган бюджет ассигнованиеләре нигезләнешләренә туры китереп булдырылган бюджет ассигнованиеләренең ни дәрәҗәдә кирәкле булып чыгуын күрсәтә.<br>Максатчан ориентир:100%<br>Күрсәткеч, тармак үзенчәлекләреннән чыгып, ел саен исәпләнелә. |
| | | | E(P)≤60% | 0 | | |
| | | | 60%<E(P)≤70% | 1 | | |
| | | | 70%<E(P) ≤85% | 2 | | |
| | | | 85%<E(P) ≤95% | 3 | | |
| | | | 95%<E(P) ≤99% | 4 | | |
| | | | 99%<E(P) | 5 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Pi – хисап чоры башына расланган җыелма бюджет росписенең і-нче күрсәткече буенча каса чыгымнарындагы тайпылыш күрсәткече. | | | | |
| 2. Чыгымнар ягыннан бюджетны үтәмәү | Күрсәткечләрне исәпләү Бюджет средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг оештыру турында тәртипкә № 11 кушымта нигезендә хәл ителә. | % | $E(P)=\sum_{i=1}^{n} E(P)_i$ $*W_i$, биредә:<br>$W_i$- Тәртипкә № 11 кушымтада күрсәтелгән і-нче күрсәткеченең саллылыгы.<br>$E(P_i)$- тәртипкә № 11кушымта нигезендә күрсәтелгән і-нче күрсәткече буенча билге | 30 | |
| 3. Керемнәр буенча бюджетны үтәү: | | % | | 10 | |
| 3.1. Керемнәр керүне планлаштыруның сыйфаты [2] | $k=\frac{1}{N}\sum_{i=1}^{N}\left(\frac{I_i}{4}\right)*\sum_{j=1}^{4}(P_{ij})$<br>$P_{ij}=1,$ әгәр $P_{fp}\leq 0{,}05$<br>$P_{ij}=\frac{P_{fp}-0.05}{0.1}$, әгәр 0,05<$P_{fp}$<0,15<br>$P_{ij}=0,$ әгәр $P_{fp}\geq 0{,}15$<br>$P_{fp}=\frac{\lvert R_{fij}-R_{pij}\rvert}{R_{pij}}$,<br>биредә:<br>N – бюджет средстволарының баш администраторларына билгеләнгән керемнәр чыганаклары саны;<br>$I_i$ =1, әгәр бюджет средстволарының баш администраторларына і-нче керем чыганагы буенча билгеләнгән керем чыганагы буенча фараз күрсәткечләрен исәпләү методикасы билгеләнсә;<br>$I_i$ =0, әгәр бюджет средстволарының баш администраторларына і-нче керем чыганагы буенча билгеләнгән керем чыганагы буенча фараз күрсәткечләрен исәпләү методикасы | % | | 70 | Бюджет средстволарының баш администраторлары өчен максатчан ориентир булып 15%.тан артмаган күрсәткеч тора. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | билгеләнмәсә;<br>$R_{pij}$ – хисап чорының j-нче кварталына айлык керемнәр фаразында билгеләнгән i-нче керемнәр чыганагы буенча керемнәр фаразы;<br>$R_{fij}$ – хисап елының j-нче кварталына керемнәрнең айлык керү фаразында билгеләнгән i-нче керемнәр чыганагы буенча касса үтәлеше. | | | | | |
| 3.1.1. Бюджет средстволарының баш администраторы буенча агымдагы финанс елына керемнәр керү фаразыннан тайпылыш[3] | $P_{fp} = \frac{\lvert R_{fi} - R_{pi} \rvert}{R_{pi}}$ , где:<br>$R_{pi}$ – хисап кварталына керемнәрнең айлык керү фаразында билгеләнгән керемнәрнең i-нче чыганагы буенча керемнәр фаразы;<br>$R_{fi}$ – хисап кварталына керемнәрнең айлык керү фаразында билгеләнгән керемнәрнең i-нче чыганагы буенча касса үтәлеше. | | $P_{fp} \leq 0,15$<br>$R_p < R_f$ | 5 | 75 | |
| | | | $0,15 < P_{fp} < 0,3$<br>$R_p < R_f$ | 4 | | |
| | | | $0,3 < P_{fp} < 0,45$<br>$R_p < R_f$ | 3 | | |
| | | | $P_{fp} < 0,15$<br>$R_p > R_f$ | 2 | | |
| | | | $P_{fp} \geq 0,15$<br>$R_p > R_f$ | 1 | | |
| | | | $P_{fp} \geq 0,3$<br>$R_p > R_f$ | 0 | | |
| 3.1.2. . Бюджет средстволарының баш администраторларының керемнәрне администрацияләү буенча норматив-хокукый базасы сыйфаты[3] | Түбәндәгеләрне үз эченә алган, бюджет средстволарының баш администраторларының норматив-хокукый актларының булуы:<br>1) Татарстан Республикасы бюджетының керем чыганакларын ведомство карамагындагы бюджет керемнәре администраторларына билгеләү;<br>2) ведомство карамагындагы бюджет керемнәре администраторларына бюджет администраторы вәкаләтләрен бирү;<br>3) исәпләп чыгару ысулы буенча бюджет учетын алып бару максатында беренчел документлар төзү (тутыру) тәртибен билгеләү;<br>4) ведомство карамагындагы бюджет керемнәре администраторларының структур подразделениеләре арасында мәгълүмат алышу тәртибе, ә түләүләр исәпләп чыгарганда – түләүләрнең төрен һәм кемнеке булуын | % | Бюджет средстволарының баш администраторының хокукый акты бу пунктның барлык таләпләренә тулысынча туры килә | 5 | 25 | Күрсәткеч Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре булып торучы артык түләнгән (түләтелгән) түләүләрне һәм алар буенча пеняларны, штрафларны кире кайтару (исәпкә алу) турында карарлар кабул итүнең дөреслегенә, аларны исәпләүнең дөреслегенә, түләүнең, исәпләүнең, учетының, түләтүнең дөреслегенә контрольлекне хәл кылу буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең администраторлары эшчәнлеген хокукый яктан |
| | | | Бюджет средстволарының баш администраторының хокукый акты бу пунктның 5 таләбенә туры килә | 4 | | |
| | | | Бюджет средстволарының баш администраторының хокукый акты бу пунктның 4 таләбенә туры килә | 3 | | |
| | | | Бюджет средстволарының баш администраторының хокукый акты бу пунктның 3 таләбенә туры килә | 2 | | |
| | | | Бюджет средстволарының | 1 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | аныклау, кире кайтару турында карарлар кабул итү;<br>5) ведомство карамагындагы бюджет керемнәре администраторлары тарафыннан бюджет средстволарының баш администраторына бюджет хисабын тапшыру тәртибе;<br>6) керем чыганакларының фараздагы күрсәткечләрен исәпләү методикасы. | | баш администраторының хокукый акты бу пунктның 2 таләбенә туры килә | | | тәэмин итүне бәяләү өчен кулланыла.<br>Күрсәткеч квартал саен һәм ел саен исәпләнелә. |
| | | | Бюджет средстволарының баш администраторының хокукый акты бу пунктның 1 таләбенә туры килә | 0 | | |
| 3.2. Керемнәр буенча дебиторлар белән исәп-хисап ясау буенча дебиторлык бурычы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеге[2] | $P = 100 * \frac{D}{R_f}$, где:<br>D – хисап чорыннан соң килүче айның 1 числосына керемнәр буенча дебиторлык бурычы күләме;<br>$R_f$ – хисап чорында керемнәр буенча касса үтәлеше. | % | P≤10% | 5 | 15 | Хисап чорыннан соң килүче айның 1 числосына керемнәр буенча дебиторлар белән исәп-хисаплар буенча дебиторлык бурычының хисап чорында керемнәр буенча касса үтәлешенә карата шактый зур күләмдә туплануы тискәре күренеш булып санала..<br>Максатчан ориентир: P=0%<br>Күрсәткеч, тармак үзенчәлекләреннән чыгып, квартал саен һәм ел саен исәпләнелә. |
| | | | 10%<P≤20% | 4 | | |
| | | | 20%<P≤30% | 3 | | |
| | | | 30%<P≤40% | 2 | | |
| | | | 40%<P≤50% | 1 | | |
| | | | P>50% | 0 | | |
